# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
# Югары Стәрле авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

Югары Стәрле авылы №23-12 «12» март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендә 115номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 14 августында142 номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 13-6, 2018 елның 24 апрелендәге 94-58,2018 елның 13 ноябрендәге 116-73 , 2018 елның 19 декабрендәге 121-76, 2019 елның 24 июнендәге 140-86,2019 елның 5 ноябрендәге 151-91 карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче елешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендә 115 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 14 августында142 номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 13-6, 2018 елның 24 апрелендәге 94-58,2018 елның 13 ноябрендәге 116-73 , 2018 елның 19 декабрендәге 121-76, 2019 елның 24 июнендәге 140-86,2019 елның 5 ноябрендәге 151-91 карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан кененнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Сабирҗанова Л.С.